ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2025 ел № 242

**Муниципаль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда – Балтач штп., Чехов урамы юл участогында берьяклы хәрәкәтне оештыру турында**

Юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау максатларында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, 2024 елгы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Балтач шәһәр тибындагы поселогында Чехов урамы автомобиль юлын эксплуатацияләү чорына юл хәрәкәтен оештыру проекты белән (ПОДД), «СПЕКТР» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ оешмасы белән эшләнгән, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда - Балтач штп., Чехов урамы юл участогында берьяклы хәрәкәтне оештырырга(Г.Тукай урамы чатыннан алып – Нариман урамы чаты белән - Ленин урамы чатына кадәр).

2. Юл хәрәкәтен оештыру проекты нигезендә(ПОДД)2024 нче елгы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Балтач шәһәр тибындагы поселогында автомобиль юлын эксплуатацияләү чорына юл билгеләрен урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә түбәндәге адреслар буенча: штп.Балтач, Ленин урамы, 45 нче йорт (2 этаж); штп.Балтач, Ленин урамы, 62 нче йорт (1 этаж); Куюк авылы, Ибрагимов урамы, 24А нчы йорт (авыл библиотекасы); Курмала авылы, Советская урамы, 21А нчы йорт(мәчет), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://baltasi.tastan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгару юлы белән һәм район «Хезмәт» газетасында.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфасын башкаручы И.Д.Габдрахманов